БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

29 май 2020 ел — № 248

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

Кешенең уңай тормыш шартларына хокукларын үтәү, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы халкы катнашында җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышу максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка федераль законнары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гавами тыңлаулар үткәрү турында» Нигезләмә хакында» 2011 елның 27 декаберендәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән 2007 елның 24 мартындагы 66 номерлы Балтач район Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р. Р. Нотфуллин